# *Галимуллина Суфия Вәлиулла кызы*

*Безнең гаиләдән әтине һәм Кәримулла абыйны сугышка озаттык.Әти Битаманнан, ә Кәримулла абый Мәскәүдә эшләгән булган,ул шуннан киткән.*
*1941 нче елны бик  авыр булды. Әнигә 4 бала калдык, бабай, әби бар иде әле тагын. Сугыш авырлыкларын ничек кичергәнне хәтерләп тә бетермим инде. Ул вакытларда ансат булмагандыр инде ул, әниләр урманнан утын ташыйлар иде, аларны каршыларга барып йөрдек әле без, чаналар этешеп кайтырга булыштык. Ул вакытта тукланырга ризык юк, черек бәрәңге дә ашадык инде...*
*Гаилә белән булгач, әнигә төшкәндер инде бар авырлык. Без бала булып калган бит инде, мәктәптә 4 класс бетергәч, фермага киттем инде эшләргә.*
*Сугыштан Кәрим абый контужен булып кайтты. Аның белән бергә яшәгәч, үзе дә безгә булышкалый иде ул, энеләрем белән бергә көтүләр дә көтеп йөрдек.*
*Сугыш вакытында, сугышка дип бөтен майлар, йомыркалар хөкүмәткә бирелә иде. Бөтен халык та шулай бирде.*
*Укый башлагач, Сафия апайлар безне башак җыярга алып чыгалар иде, ул башакларны чиләкләргә, сумкаларга җыеп, әвенгә илтә идек.*
*Сугыш бетү, җиңү турында бөтен халык бергә ишеттек инде, мәктәпләрдә дә әйтелде сугыш беткәне. Шунысы кызганыч: әтиләр генә кайтмады.*
*Сугыштан безнең күрше Бибиҗәләл апайның ире Ибрай абый кайтты. Аны әбиләр кунакка алып чыгып, сугыш турында сөйләтәләр иде.*
*Сугыш беткәч тә, ул авырлыклар бик озак барды бит әле. Мин монда тормышка чыккач кына, 5 тиен акча бирә башладылар миңа. Әле  элек эшләгәндә бушка эшләү булды бит.*
*Ул вакытта әниләр белән бергә булганлыктан, бик эш булмаган. Авырлыкларны гаилә белән бергә күргән инде.*
*Хәзерге яшь буынга андый авырлыклар булмасын иде.*